ГЛАВА КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

08.11.2024 — д. Канаш — __ 4 номерлы

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Түбән Күл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Уставынаың 24 ст. туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 20 ноябрендә 11.00 сәгатькә Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегенең Түбән Күл авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә;

1.1. 2024 елның 20 ноябрендә 12.00 сәгатькә Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Түбән Күл авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләп үтәргә;

1.2. 2024 елның 20 ноябрендә 13.00 сәгатькә, Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Түбән Күл авылы гражданнары арасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

2. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүлү.
1 этап: Түбән Күл авылы, Үзәк урамында яшәүчеләр (9нчы йорттан 10нчы йорт) ;
Түбән Күл авылы, Мәктәп урамында яшәүчеләр (1 нче йорттан 23 нче йорт);
2 этап: Түбән Күл авылы, Яшьләр урамында яшәүчеләр (1нче йорттан 33нче йортка кадәр);
3 этап: Түбән Күл авылы, Боевая урамында яшәүчеләр (1нче йорттан 40нчы йортка кадәр)

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегенең Түбән Күл авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү

«ӘЙЕ» «ЮК»

4. Гражданнар җыеннарын уздырырга

1 этап: Түбән Күл авылы Мәктәп урамы буенча 10-нчы номерлы йорт янында;

2 этап: Түбән Күл авылы Яшьләр урамы буенча 12-нче номерлы йорт янында;

3 этап: Түбән Күл авылы Боевая урамы буенча 22-нче номерлы йорт янында

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Вальков